СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.02.2026 Баулы шәһәре № 31

Баулы муниципаль районы Иҗтимагый
советы составының өчтән берен
раслау турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районының Иҗтимагый советы турында» 2024 елның 9 февралендәге 236 номерлы карары нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Иҗтимагый советы составының өчтән берен кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль район Советының
2026 елның 5 февралендәге
31 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Баулы муниципаль районының
өченче Иҗтимагый советы
составы

| | | |
|---|---|---|
| Вильданова Ольга Вячеславовна | - | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Ю.А.Гагарин исемендәге 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе педагогы (килешү буенча); |
| Гайсина Лилия Хәкимҗан кызы | - | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ сәламәтлек саклау хезмәткәрләренең беренчел профсоюз оешмасы профкомы рәисе (килешү буенча); |
| Гарифуллина Ләйсән Ринат кызы | - | Татарстан Республикасы Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан республика оешмасының Баулы район иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча); |
| Гыйმранова Фәнилә Сәгыйть кызы | - | «Россия пенсионерлары берлеге» ҖЧҖнең Баулы бүлекчәсе рәисе (килешү буенча); |
| Дәүләтова Елена Анатольевна | - | Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсенең Баулы бүлекчәсе рәисе (килешү буенча); |
| Ткачев Роман Владимирович | - | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «1 нче спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль автоном учреждениесе директоры. |